**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

18.08. 2025 ел № 929

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә файдаланылган терекөмеш лампаларны туплау урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 12 апрелендәге 108 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары белән, тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортировкалау һәм урнаштыру гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә, эш итү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары таләпләрен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә файдаланылган терекөмеш лампаларны туплау урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 12 апрелендәге 108 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктта «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмат стендларында (стойкаларында)» сүзләрен «федераль дәүләт әйләнә-тирә мохит торышы мәгълүмат системасында» сүзләренә алыштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Г.Даутов